РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:
«Социаль әһәмиятле барлык чыгымнарга акча табылды»

> 2

ИГЕЛЕКЛЕ ҺӨНӘР:
табиблар һәм укытучылар беренче өчлектә

> 3

ХАЛЫКНЫКЫ ИДЕ!
Зифа Басыйрованы сагыну

> 3

ТАҢСЫЛУ ХЫЯЛЛАРЫ
Ул язмыш тарафыннан шактый сыналган

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 174 (28756) | Сишәмбе | 30 ноябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

БАРДАН ЮК ЯСАМАСКА

СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ, ДАРУ ҖИТӘРЛЕК, ДИ

Узган атна ахырында, даруханәләрдә иң кирәкле даруларга кытлык башланачак, дигән хәбәр таралды. Сүз коронавирус, грипп һәм салкын тигәндә эчәргә кирәкле дарулар турында бара. Һавадан алып әйтелгән сүзләр түгел бу. Иҗтимагый куллану инициативасы (ОПИ) рәисе Олег Павлов Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсенә (Росздравнадзор) шундый эчтәлектәге хат юллаган. Даруларга кытлык кичерәчәк дип фаразланган төбәкләр исемлегенә Татарстан да эләккән.

Ике көннең берендә коронавирус котыра ише сүзләрне ишетеп яшәгән көннәрдә даруханәләрдә дарулар җитми башлаячак дигән хәбәр аяз көнне яшен суккандай булды, билгеле. Чирне дәвалау гына түгел, аны кисәтү, аннан соң тернәкләнү өчен дә төймә кабарга иялəшеп беттек инде. Шомлы хат авторы сүзләренә караганда, илдәге даруханәләр сезонлы даруларга ихтыяҗ артуга әзер түгел. «Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы коронавирусны дәвалаганда кулланырга тәкъдим иткән күп кенә даруларны (фавипиравир, парацетамол, умифеновир, апиксабан, ривароксабан) кайтартканда кыенлыклар килеп чыга башлады инде. Красноярск крае, Татарстан Республикасы, Волгоград, Түбән Новгород һәм Новосибирск өлкәләрендә хәлләр аеруча мөшкел», – диелә хәбәрдә.

Бу хәбәр таралып озак та үтмәде, Татарстан сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков рәсми белдерү белән чыкты. Министр сүзләренә караганда, республикада сезонлы даруларга кытлык юк. ОРВИ һәм коронавирусны дәвалау өчен кирәкле дарулар ел азагына кадәр җитәрлек күләмдә сатып алынган.

– Без Росздравнадзор идарәсе белән берлектә барлык шәхси һәм дәүләт даруханәләрен йөреп чыктык. Дефицит юк. ОРВИ белән коронавирус инфекциясен амбулатор шартларда дәвалау өчен дарулар алуга федераль һәм республика бюджетларыннан акча алдык. Алар ел азагына кадәр җитәрлек күләмдә сатып алынды, – дип ышандыра Марат Садыйков.

Сүздән эшкә күчеп, министр әйткәннәрнең хаклыгын тикшереп карарга булдык. Коронавирус вакытында иң еш кулланыла торган даруны (ривароксабан) сайлап, үзебезнең яндагы беренче даруханәгә шалтыраттык. Биредә аның төймәләр санына карап төрле дозада һәм төрле бәядәге барлык төрләре дә бар булып чыкты. «Башка төрле препаратларга да кытлык юк. Безнең бөтен челтәрдә дә бар алар. Гади парацетамолдан башлап, барысы да сатуда», – диде безнең белән аралашкан фармацевт кыз. Казан шәһәре даруханәләренең бердәм белешмә хезмәтендә дә шул ук сүзне кабатладылар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рәсми саннардан аңлашылганча, соңгы өч айда Россиядә дарулар 5–10 процентка кыйммәтләнгән. Даруларга кытлык барлыкка килсә, аларның бәясе тагын да артачак, дип фаразлый белгечләр. Танылган блогер, Казандагы даруханәләр челтәре хуҗасы Гөлия Вәлиәхмәтова бу фикер белән килешми. «Ел азагына кадәр дару бәяләре артмас. Әле ноябрь азагында гына барлык төбәкләрдә яшәү өчен мөһим булган даруларның бәясе төште», – ди ул. Эшмәкәр сүзләренә караганда, хәзерге вакытта даруханәдә вируслы авыруларга, шул исәптән ковидка каршы даруларга кытлык юк.

– Аларга ихтыяҗ артты. Дөрес, аларны кайтартканда тоткарлыклар бар. Әмма бу күбрәк QR-кодлар кертелү белән бәйле. Күмәртәләп сатучы оешма хәзер, товарны алгач, һәркайсының QR-кодын тикшерергә тиеш. Бу – бик күп вакыт таләп итә торган өстәмә эш. Шуңа күрә элек заказга бирелгән дарулар безгә көненддә үк китерелгән булса, хәзер аны бер көннән соң гына алабыз, – ди Гөлия Вәлиәхмәтова. – Даруларга кытлык булмаячак. Һәрхәлдә, дистрибьюторлар бу хакта алдан кисәткән булыр иде. Ноябрь башында: «Ай азагында «Арбидол»га сорау зур булачак, күбрәк алыгыз, дип әйткәннәр иде. Бу даруга сорау, дөрестән дә, зур булды. Ләкин ул әле дә сатуда бар. Башка андый-мондый кисәтү булмады.

Сүз уңаеннан, белгечләр якын арада даруханәләрдә яшәү өчен мөһим булган дарулар да кимергә мөмкин дип фаразлый. «Дару җитештерүчеләр ике ел рәттән әлеге төр дарулар запасын арттырмый. Ник дигәндә, алардан әллә ни зур табыш алып булмый. Росздравнадзор тарафыннан җитди тикшерүләр башланса, бу мәсьәлә җайга салыныр иде», – дип өметләнә Олег Павлов. Күптән түгел Россия Федерация советы коронавируска каршы уйлап табылган яңа даруны да яшәү өчен мөһим булган дарулар исемлегенә кертергә тәкъдим итте. Билгеле булганча, 12 ноябрьдә Россиядә коронавируска каршы үзебездә җитештерелгән «Арепливир» исемле беренче дару теркәлде. Ел ахырына кадәр аны хастаханәләрдә куллана башларга уйлыйлар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Алдынгылар рәтендә

Татарстан социаль-икътисади үсеш буенча рейтингта 15 төбәк исәбенә кергән. Мәскәү, Ямал-Ненец автономияле округы һәм Төмән өлкәсе исә исемлектә – беренче өчлектә. «Иң-иң»нәр унлыгында – Ханты-Манси автономияле округы, Санкт-Петербург, Ленинград, Чиләбе, Курск өлкәләре, Якутия, Приморье крае. Ә менә Мәскәү, Калуга өлкәләре, Магадан, Иркутск ярты ел эчендә унлыктан төшеп калган.

2021 елның беренче яртыеллыгы өчен төзелгән рейтингка барлыгы 33 төбәк кергән. Татарстан, инде әйткәнебезчә, Калуга, Белгород, Мәскәү һәм Тула кебекләр белән беррәттән, икенче дистәгә эләккән. Ә Владимир һәм Магадан өлкәләре рейтингта соңгы урыннарны алган.

Политтехнолог Александр Твердов фикеренчә, ел йомгаклары асылда пандемиянең яңа «дулкын»ы, чирләүчеләрнең артуы сәбәпле, бизнесның ни дәрәҗәдә зыян күрүенә, төбәкләр башлыклары гамәлләренә бәйле булачак. Аның фикеренчә, Татарстан һәм Мәскәү өлкәсе лидерлар унлыгына керергә мөмкин.

Балалы гаиләләр түләми

Балалы гаиләләр күчемсез милек сатудан салым түләмәячәк. Әмма бер шарты бар: сатудан кергән акча әйбәтрәк яңа торак сатып алуга тотылырга тиеш. Россия Президенты Владимир Путин бу җәһәттән тиешле законны имзалаган. Документ Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында басылып чыккан.

Бу мөмкинлек быел 1 гыйнвардан төзелгән күчемсез милек белән алыш-бирешләргә кагыла. Моның өчен гаиләдә кимендә ике бала (балигъ булмаганнар һәм 24 яшькә кадәрге көндез укучы студентлар күздә тотыла) булырга тиеш. Сатудан керем буенча салым түләүдән ата-аналар, шулай ук бер бала азат ителергә мөмкин.

Шунысы да бар: яңа торакның искесен сатканнан соң бер ел эчендә сатып алынуы кирәк (әмма киләсе елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча). Сатылган торакның кадастр бәясе 50 миллион сумнан артмаска, шулай ук аңа алмашка сатып алынганының кадастр бәясеннән кыйммәтрәк булмаска тиеш. Шул ук вакытта гаилә әгъзаларының торак сату вакытына башка фатирга ия булмаулары шарт.

Мәктәпкә – электрон чират

Киләсе елда мәктәпкә беренче һәм унынчы сыйныфка язылу өчен электрон чират пәйда булачак. Балалар бакчасына гариза тапшыру үрнәгендә, мәктәпкә электрон чиратны беренче сыйныфка кабул итү чоры җиткәч – 1 апрельдән башлап җибәрү күздә тотыла. Шулай итеп, әти-әниләр сабыйларын беренче сыйныфка интернет аша яза алачак. Шул ук вакытта гариза гына түгел, барлык документлар да электрон рәвештә кабул ителәчәк. Бу исә укытучыларга да, ата-аналарга да вакытны янга калдыру мөмкинлеге бирә. Шуннан соң бала исәпкә алыначак, әти-әниләр чиратны күзәтеп торачак. 10 һәм 11 нче сыйныфта укуын дәвам итәргә теләүчеләргә дә шундый мөмкинлек ачыла.

Һава торышы үзгәрүчән

Россиянең Европа өлешендә (димәк, бездә дә) быел кышын һава торышы гел үзгәреп торачак. Көчле салкынның кинәт кенә җепшеккә алышыну очраклары еш күзәтеләчәк дигән сүз. Россия Гидрометеоүзәге фәнни җитәкчесе Роман Вильфанд «РИА Новости» хәбәрчесенә әйткәнчә, бу глобаль җылынуга бәйле. «Фаразларга караганда, быел кышын һава шартларының еш үзгәреп торуын күрергә туры киләчәк. Суыгы да, җылысы да булачак. Температурадагы кискен тирбәлешләр климат җылынуга бәйле», – дигән белгеч.

Аның әйтүенчә, 20 градуска кадәр суыткан көннәр аз булмаячак. Шул ук вакытта, көньякның җылы һавасы үтеп керү сәбәпле, суыкның җепшеккә алышыну очраклары еш күзәтеләчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Көн кадагында

Алмак бирмәк белән ярышыр

Күрсәтмәгәч, күрмиләр инде. Исегездә булса, элегрәк ришвәтчелек мәсьәләләренә бәйле матбугат очрашуында кырын эшләрне кисәтүдә социаль челтәрләрнең әһәмияте турында әйткәннәр иде. Бу юлы матбугат көчен телгә алдылар. Белгечләр әйтүенчә, мәгълүмат чараларының әһәмияте шулай ук зур. Кулланырга гына кирәк.

Кызыксыну юк

Татарстан Президентының Ришвәтчелеккә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе баш киңәшчесе Салават Рәхимов әйтүенчә, ел башыннан бирле республикада төбәк хакимиятләренең 3,3 меңнән артыграк карары ришвәтчелек күренешләре китереп чыгару-чыгармау ихтималына тикшерелгән. Бары тик 30ында гына хокук бозу ачыкланган. Гомуми күрсәткечнең 1 процентыннан да кимрәк бу. 26 меңләп муниципаль хокукый актларда аннан да азрак хилафлыклар тапканнар.

Әллә барысы да шундый намуслы, әллә кырын эшләрне тикшерүгә кызыксыну азрак. Һәрхәлдә, республикада икенчесе күзәтелә инде. Салават Рәхимов әйтүенчә, Татарстан халкы хакимият карарын коррупция күренешенә карата сирәгрәк тикшерә башлаган. Ә хакимият үз карарларында ниндидер хата-кимчелекләр тапмый диярлек.

– Юстиция министрлыгында аккредитация узган физик һәм юридик затлар да тикшерүләр үткәрә ала. Татарстанда андый белгечләр саны шактый кимеде: нибары 22 физик һәм 3 юридик зат бар. Сөендерерлек сан түгел инде бу, – диде Президент киңәшчесе.

Кырын эшләрне барлауда халыкның да ярдәме кирәк.

– Безгә сезнең белән актив хезмәттәшлек кирәк. Без сезнең белән законнарның чисталыгы турында сөйләшәбез, – ди Салават Рәхимов.

«Фатир»лы укучылар, туганнар династиясе…

Мәгариф өлкәсендә ришвәтчелеккә бәйле очраклар балаларны 1 нче сыйныфка кабул итү, дистанцион рәвештә гариза тапшыру, мәктәпләрдә җитәкчелек итү кебек юнәлешләрдә ачыклана. Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары, министрлыкның Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе Рәмис Мөҗипов әйтүенчә, белем бирү сыйфаты кайда да бер булса да, ата-аналар ул-кызларын «кәттә» саналган мәктәпләргә бирергә ашкына. Моның өчен әллә нинди адымнарга да баралар. Хәтта балаларын яшәми торган фатирларга «прописка»га кертәләр икән. Мондый очраклар башкаланың 182, 185, 186, 187 нче лицейларында, 179 нчы гимназиядә ачыкланган. Нигездә мондый кырын алымнан белем бирү үзәкләре булмаган Казан бистәләрендә яшәүчеләр файдалана. Балалары шәһәр мәктәпләренә укырга керсен өчен, аларны Казанда теркиләр.

Иң кызыгы – интернетта мондый вакытлы «прописка» сату буенча тәкъдимнәр дә күп. Хакы да билгеләнгән. «3 ай фатирда «яшәү» бәясе – 3 мең сумнан, 5 ел дисәң, 14 меңнән башлана», – диде Рәмис Мөҗипов.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Галина ВӘКИЛОВА, Татарстанда коронавируска каршы вакцина ясаткан 2 миллионынчы кеше:

Миңа калса, Татарстан вакцина ясатучылар саны буенча алдынгылар сафында булырга тиеш. Безнең өйдә барысы да ясатты. Бер оныгым Лондонда яши. Шалтыраткан саен кабатлый, әби, ясатырга кирәк, ди. Табиб та шулай диде. Кешеләр үзләре һәм якыннары гына түгел, тирә-яктагылар өчен дә җаваплы булырга тиеш. Шулай булганда гына коронавирусны җиңә алачакбыз.

ТАТАРСТАНДА – ХАТЫН-КЫЗЛАР

2021 ел башында республикада 2089,9 мең хатын-кыз яшәгән. Бу – бар халыкның 53,7 проценты.

16 яшьтән кечерәкләр……**374,4** мең
16–55 яшьлекләр…………**1041,2** мең
Яше 55тән узганнар………**674,3** мең

1000 ИР-ЕГЕТКӘ НИЧӘ ХАТЫН-КЫЗ ТУРЫ КИЛӘ?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АФРИКА ШТАММЫ: КУРКЫНЫЧМЫ, ЮКМЫ?

Үткән атна ахыры тарихка дөньякүләм яңа бала – коронавирусның «Омикрон» дип тамгаланган яңа штаммы белән язылды. Яңа вариант әлегә ныклап өйрәнелмәгән булуга карамастан, аның турында берсеннән-берсе куркыныч хәбәрләр пәйда булды. Ул вакциналанган кешеләргә дә бик җиңел йога, 25 яшьтән яшьрәкләргә һәм балаларны да аямый, бик тиз йога һәм тарала дигән сүзләр планетаны бик тиз әйләнеп чыктылар һәм биржа индексларын, чимал бәяләрен түбәнгә этеп төшерделәр. Тулысынча диярлек вакциналанган Израильдә (анда икe вакцина ясатучыларның вакциналары дип санныйлар, бары тик өченче көчәйткән доза (бустер) алучыларны гына прививкага ия дип табалар) әле яңа штамм турында хәбәр таралганчы ук биленче дулкын башланачагы турында рәсми рәвештә игълан иткәннәр иде инде. Көньяк Африка Республикасыннан өч тапкыр вакциналанган хатын чир иярткән кайткач, алар ашыгыч рәвештә чикләрне бикләргә керештеләр, хөкүмәтнең ашыгыч киңәшмәсен җыйдылар. Ул арада Европа илләреннән «Омикрон» табылган дәүләтләр белән элемтәне өзү турында рәсми хәбәрләр яңгырады. Әмма серле штамм инде Европага килеп җиткән һәм үз эшен башлаган иде. «Комсомольская правда» газетасының «Телеграм» каналы «Омикрон»ның Россиягә дә килеп җитүе турында аваз салды, ләкин Роспотребнадзор бу хәбәрне кире какты.

Бөекбритания Сәламәтлек саклау министрлыгының төп киңәшчесе: «Яңа Көньяк Африка штаммы – без моңа кадәр күргәннәре арасында иң куркыта торганы», – дип сөрән салды. Ил Премьер-министры Борис Джонсон яңа штаммның вакциналанган кешеләр арасында да таралуын искәртеп, Англиядә яңа ковид-чикләүләр кертелүен игълан итте. Бөтендөнья медицина ассоциациясе башлыгы Франк Ульрих Монтгомери «Омикрон»ны «Эбола» белән тиңләп, кешеләрнең котын алды. Хәзерге вакытта чирнең таралу дәрәҗәсе һәм географиясе турында мәгълүматлар сәгать саен үзгәреп тора. Чикләр бикләнә. Россия да 28 ноябрь төне уртасыннан Көньяк Африка Республикасы, Ботсвана, Лесото, Намибия, Зимбабве һәм башка күп кенә Африка илләре белән араланышны 1 февральгә кадәр туктатты. Тик инде яңа штаммның Европада таралуын искә алганда, чикләрне тулысынча ябу гына нинди дер нәтиҗәләр бирә алачак.

Башта бар хальыкларны куркыткан Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы исә яңа вариантның алай куркыныч булмавы ихтималлыгын да әйтеп, чикләрне япмаска өнди башлады.

Анжелика Кутузи – Көньяк Африка медицина ассоциациясе рәисе – яңа штаммның бик җиңелчә генә авыру китереп чыгаруын, бер-ике көннән үтүен, ис һәм тәм сизүнең югалмавын әйтеп, ни өчен бу уңайдан шулкадәр шау-шу кубуын аңламавы турында хәбәр таратты. Вәләкин инде финанс базарларында туңгәрелеш башланган, нефть арзанайган, рус сумы долларга карата курсын түбәнәйткән, шул исәптән Көньяк Африка валютасы да «егылган» иде. Кутузиның тынычландыруын берәү дә игътибарга алмый, чөнки хәбәрләрнең куркынычрагы гадәттә дөресрәк булып чыга. Әлегә көчәйтелгән штаммнан башка да хәлләр җиңел түгел. Кат-кат вакциналанган Чехия Президенты Милош Земан коронавирус йоктырды һәм Премьер-министр кандидатурасын пыяла эчендә утырган халдә генә раслады.

Россиядә

ШАРТЛАУДАН СОҢ

Россиядәге вазгыятьне шул сүзләр белән бәяләп булыр иде. 25 ноябрь көнне «Листвяжная» шахтасында метан һава катнашмасы шартлавы нәтиҗәсендә булган авария үткән атнаның төп вакыйгасына әйләнде. Бу юллар язылганда фаҗигадә 51 кешенең үлүе турында мәгълүм. Кемерово өлкәсе хакимиятләре авария белән бәйле рәвештә гадәттән тыш хәл режимы керттеләр. Бу инде башка шахталар да тикшерелә дигән сүз. Әлегә тикшерү нәтиҗәсендә 450гә якын кагыйдә бозу очрагын ачыкладылар, 180 административ эш кузгатылды. Шик юк: фаҗигаңнең төп сәбәбе – күмер чыгару артыннан куып, куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен үтәмәү. Шахта җитәкчелеге генә түгел, шахтерлар үзләре дә рөхсәт ителмәгән адымнарга бик теләп барганнар, чөнки хезмәт хаклары чыгарылган күмер күләменә бәйле. Һавадагы метан күләмен күрсәтүче «маяк»ларны ачып, контакларны ябыштырып куючылар булган. Шулай эшләгәндә, я прибор бөтенләй сафтан чыга, яисә газ күләмен түбәнәйтеп күрсәтә икән. Датчиклар тавыш кубармасын өчен, өсләренә калын өс киемнәре ыргытып куюо да гадәткә кергән. Хәзер инде кемнәрнең ни дәрәҗәдә гаепле булуларын тикшерүчеләргә ачыкларга туры килә.

Ваемсызлык – илдәге вазгыятьне формалаштыручы төп сәбәп әнә шул. Әйтик, «Роснано»ның 280 миллиард сумнан артык акчаны суга салып, банкротлык чигенә килеп җитүендә менә шул начар сыйфат гаепле. Хәзер инде инвесторлар (биржа спекулянтлары) хөкүмәттән салым түләүчеләр акчасы белән «Роснано»ны коткаруын таләп итәләр. Ә компаниянең ничек эшләве белән бөтенләй кызыксынмыйча гына аның кыйммәтле кәгазьләренә зур акчалар тотуларында үзләрен бер дә гаепләмиләр. Күптән түгел генә компания җитәкчелеге кредиторлар һәм облигация тотучылар белән ябык утырыш үткәрде. Утырышның нәтиҗәләре куанычлы түгел, диләр. Инвесторларга байтак акча югалтырга туры килачәк. Менә шул югалтуны хөкүмәт җилкәсенә аударып судан коры чыгарга телиләр, компания банкротлыкка чыкса, бөтен ил буйлап финанс тотрыклылыге башланачагы белән куркыталар. Ябык утырыштан соң «Роснано» облигацияләре 30 процентка кадәр арзанайды.

Бер «Роснано» гына түгел, россиялеләрнең күпчелеге банкротлык халәндә бүген. Әлләүче халыкның 70 проценты кредитларга баткан. Ике-өч кредит алып түли алмыйча интегүчеләр саны кискен үсә. Бөтен халыкка туры килгән акчаларның 50 проценты менә шулар җилкәсендә. Беренче кредит алучылар үзләрен «Роснано» кебек хис итәләр: дефолт игълан итәргә, ягъни акчаларне түләүдән баш тартырга телиләр. Әҗәт җыючыларның гына түгел, аларга кредит бирүчеләрнең дә ваемсызлыгы тудыра нечар вазгыятьне. Бәяләр шул сәбәпле күтәрелә, инфляция тәгәрәмчен шулар әйләндерә. Дизель ягулыгы гына да ел башыннан җиденче тапкыр рекордлы кыйммәтләнгән бит инде. Менә шундый шартларда федераль хөкүмәт Венгриягә атом станциясе төзү өчен бирелгән 10 миллиард долларлык кредитны (750 миллиард сум) түләүне 10 елга кичектерергә рөхсәт итте. Мондый кин күңеллелек ил икътисады өчен кыйммәткә төшә, билгеле.

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«ҺӘР БЮДЖЕТ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ»

Көн кадагында

Узган атнада Дәүләт Советында «2022 елга һәм плангагы 2023–2024 еллар чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Закон кабул ителде. Беренче укылыштан соң аңа нинди үзгәрешләр кертелгән? Дефициттан ничек котылып булачак? Агымдагы бюджет ничегрәк үтәлә?Бу сорауларга җавап табу өчен документны турыдан-туры эшләүчеләрнең берсе – финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИНга мөрәҗәгать иттек.

:: Радик Рәүфович, икенче укылышка 500дән артыграк төзәтмә кертелде. Аларның барысын да диярлек Хөкүмәт керткән. Бу нигә бәйле һәм ни өчен депутатлардан төзәтмәләр аз?

– Бу хәл бюджетны төзегәндә үк депутатлар белән тыгыз элемтәдә торып эшләвебезгә, аларның, сайлаучыларның теләк-тәкъдимнәрен исәпкә алуыбызга бәйледер, дип уйлыйм. Кертелгән төзәтмәләр асылда, федераль үзәктән өстәмә акчалар һәм республика бюджетыннан федераль программалар, илкүләм проектлар чыгымнарын күтәрешү зарурылыгы ягыннан, бюджетны тәгаенләштерүгә юнәлдерелгән. Төзәтмәләр чынбарлыкта – 50 генә, калганнары берсен-берсе кабатлый. Шул ук вакытта һәр төзәтмә бюджет классификациясенең бернича кушымтасында чагылдырыла, бүлекләре һәм статьялары буенча тәгаенләштерелә. Нәтиҗәдә аларның саны дистәләрчә тапкыр күбәя.

Шул рәвешле 2022 елга расланган бюджетта федераль средстволарның гомуми күләме – 54,1 миллиард сум, 2023 елга – 52,4 миллиард сум, 2024 елга 50,6 миллиард сум тәшкил итә.

Татарстан ягыннан чыгымнарны күтәрешү өчен бюджетның чыгым өлешен 2022 елга – 3,2 миллиард сумга, 2023 елга – 2 миллиард сумга арттыру, шулай ук бу максатта резервланган республика бюджеты акчасын аерым юнәлешләргә бүлү таләп ителә.

Хезмәткә түләүнең минималь күләме (МРОТ) һәм бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакы күләме арту сәбәпле, бюджет чыгымнары һәр ел саен 5,5 миллиард сумга үсә. Шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләрен шәхси сак предприятиеләре тарафыннан саклауга чыгымнар 1,1 миллиард сумга күбәя. 3 һәм 7 яшькә кадәрге балалар өчен айлык пособие алучылар саны ишаю сәбәпле, киләсе елда бу җәһәттән чыгым 2 миллиард сумга арта.

2022 елга Татарстан Республикасы бюджеты керемнең гомуми күләме 300 миллиард 32 миллион 686 мең 500 сум тәшкил итә. Чыгымнарның гомуми күләме – 324 миллиард 46 миллион 421 мең 400 сум. Киләсе елга Татарстанның бюджет дефициты 24 миллиард 13 миллион 734 мең 900 сум тәшкил итә.

:: Республика бюджеты дефициты күләме инде беренче укылышта ук аз түгел иде. Хәзер тагын да арткан. Үтәлмәгән бурычлар калмасмы? Җитмәүчелекне ничегрәк каплау планлаштырыла?

– 2022 елга бюджет дефициты 14 миллиард сумга диярлек артса да, финанслауны чыганаклары белән тулысынча тәэмин ителгән ул. Бу мәсьәлә һәрвакыт җитди игътибар таләп итә. Быелгы бюджет акчасы калдыкларын киләсе елда бюджет дефицитын каплауга тотачакбыз. Бүген шуны әйтә алабыз: 2022 елга бюджет максималь дәрәҗәдә балансланган кителәчәк.

:: Бюджет кабул итү финансистлар өчен бәйрәм кебектер, мөгаен. Министрлыкның гаять зур эш йомгагы булып тора бит ул. Хәзер инде киеренке эштән соң бераз ял итәргә дә мөмкиндер?

– Әйе, берникадәр киеренкелек кимеде. Әмма инде, 1 гыйнвардан бу документта күздә тотылган барлык чаралар акча белән өзлексез тәэмин ителсен өчен, бюджет турында законны тормышка ашыруга кирәкле норматив документларны әзерләү чоры җитте. Гадәти, ләкин гаять зур игътибар таләп итә торган эш бу. Һәр сан артында бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакы, сәламәтлек саклау, мәгариф учреждениеләрен кирәкле җиһазлар белән тәэмин итү һ.б. ята бит.

Кабул ителгән чыгым йөкләмәләре нигезендә, бюджет оешмалары финанслау системасы корыла. Бюджет акчасын баш бүлүче, ягъни билгеле бер министрлык яисә ведомство бюджет акчасын алучы (мәктәпләр, хастаханә, китапханәләр һ.б.) буенча тиешле сметалар төзи. Бу сметаларның штат расписаниеләренә, төзелгән килешүләргә, бюджет акчасы хисабына тегe яки бу чараларны үткәрү зарурылыгына туры килү-килмәве тикшерелә. Шуннан соң, кварталларга, чыгымнар статьяларына бүлеп, барысы бергә тупланыла – бу документ бюджет росписе дип атала. Аның буенча оешмалар киләсе елда казнадан акча ала. Муниципаль районнар һәм шәһәр округларына җибәреләчәк акчалар да шулай ук тәгаенләштерелә. Без алар белән өч формада: бюджеттан тәэмин ителешне тигезләү, үзләренә тапшырылган вәкаләтләрне финанслау, башка трансфертлар бирү формасында эшләячәкбез.

:: Узып баручы финанс елына ниндирәк бәя бирер идегез? Ел азагына кадәр бюджет ничегрәк үтәләчәк?

– Һәр бюджет, уникаль, дип бәяләргә мөмкин. Ул, шул төр кебек үк, үзенең үзенчәлекләренә ия чөнки. Узган елда дөнья икътисадының гаять зур кыенлыклар алдында калуын, керемнәр күләме кимүен яхшы хәтерлибез. Шуңа да карамастан, беренче чиратта кирәкле һәм социаль әһәмиятле барлык чыгымнарга акча табылды, дәүләт заданиеләре буенча эшләргә түләнелде, илкүләм проектлар һәм республика максатчан программалары тулысынча финансланды.

Быел барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның керем өлешен үтәү уңай яктан бәяләнә. Нәтиҗәдә планлаштырылган барлык чыгымнарга акча табыла, программалар уңышлы тормышка ашырыла.

Халыкка социаль түләүләр белән беррәттән, кече һәм урта бизнеска ярдәм күрсәтелә. Агымдагы елда муниципаль район җирлегендә урнашкан сәнәгать паркы территориясендә эшләүчеләргә кайбер салымнар буенча яңа ташламалар билгеләнде.

2020 елда федераль үзәктән бирелгән бюджет кредитлары буенча бурычны реструктурлаштыруны да быелгы финанс елының үзенчәлеге буларак бәяләргә мөмкин. 2021 елның 11 аенда Татарстан тупланма бюджетына 298,7 миллиард сум күләмендә салым һәм салым булмаган керемнәр алынды.

Республика бюджетына салым һәм салым булмаган керемнәр күләме 250,6 миллиард сум тәшкил итте. Җирле бюджетларның үз керемнәре 48,1 миллиард сум күләмендә тупланды.

Ел азагына кадәр безгә – финансистларга бюджетның керем өлешен үтәү, салымның җыелмый калган өлешен киметү, республика бюджеты акчасыннан һәм федераль средстволардан үз вакытында, нәтиҗәле һәм тулы күләмендә файдалануны булдыру эшен дәвам итәргә кирәк. Республиканың барлык предприятиеләре һәм оешмаларының, һәрбер хезмәткәр һәм белгечнең нәтиҗәле эшләвенә турыдан-туры бәйле бу. Форсаттан файдаланып, республикабызның төп газетасын укучыларның һәммәсенә нык сәламәтлек һәм иминлек телим.

Әңгәмәдәш – Диләрә СӘГЪДӘТШИНА

ДӘРӘҖӘНЕ КЕМНӘР ТӨШЕРӘ?

КООПЕРАТИВЛАРГА БЕРЛӘШҮНЕҢ ФАЙДАСЫ КҮБРӘК

Борчылу

Авыл хуҗалыгы продукцияләре җитештерү буенча Татарстан – илдә әйдәп баручы төбәкләрнең берсе. Әмма бездә дә кичекмәстән хәл итәсе проблемалар хәттин ашкан. Шуларның берсе – авыл җирлегендә төрле кооперативларга берләшеп, яңа эш урыннары булдыру.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы җитәкчеләре, муниципаль район башлыклары һәм купсаны белгечләр катнашында республиканың дүрт төбәгендә узачак зона киңәшмәләрендә шул турыда җитди сөйләшү булачак.

Ел ахырына санаулы көннәр генә калып барганда, авыл хуҗалыгында кайбер нәтиҗәләр турында фикер йөртергә була. Кызганыч, әмма алар әллә ни шатланырлык түгел. Корылык һәм пандемия афәте күп кенә мөмкинлекләрне тормышка ашыруга киртә куйды.

Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әйтүенчә, югалтулар хәтта Россия күләмендә авыл хуҗалыгы эш нәтиҗәләре белән чагыштырганда да зуррак. Тулаем продукция җитештерү күләме узган елның шул чоры белән чагыштырганда Россиядә 4,3 процентка кимегән булса, Татарстанда түбән тәгәрәү 11,9 процент тәшкил итә. Ел дәвамында запас частьлар – 28, ягулык-майлау материаллары – 22, минераль ашлама бәяләре 66 процентка артканда, табышлы эшләү турында хыялланырга гына кала шул инде.

Бу турыда сүз алып барганда, ирексездән «суга батучыны коткару – батучының үз эше» дигән гыйбарә хәтергә төшә. Бернинди кыенлыкларга карамыйча, авылда үз кыйбласын табып, шәхси һәм фермер хуҗалыкларында елдан-ел югарырак нәтиҗәләргә ирешүче фидакарьләргә корылык та, җитештерелгән продукциягә тиешле бәя булмау да киртә түгел. Игенчелек, терлекчелек һәм башка тармакларда берсеннән-берсе югарырак нәтиҗәләргә ирешә андыйлар. Нигездә үз тырышлыклары белән көн күрсәләр дә, дәүләт ярдәменнән дә баш тартмыйлар. Нәтиҗәдә шәхси хуҗалыкларда мөгезле эре терлекнең баш саны 290 меңгә җитсә, фермер хуҗалыкларында сыер саны 4200гә арткан.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, республикада 2021 елда төрле дәүләт программаларында катнашып, авылда кече эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче, шәхси һәм фермер хуҗалыкларына күпләп мал-туар, кошкорт асраучылар дәүләттән 676 миллион сумлык ярдәм алган.

Эшләргә теләге булганнар җаен таба үзе. Нурлат районы башлыгы Алмаз Әхмәтшин сүзләренә караганда, авылларда кулыннан эш килә торган егет-кызлар әле дә байтак. Аларны табарга, ярдәм итәргә, кызыксындыра белергә генә кирәк. Гаҗәп, әмма факт: ел дәвамында Нурлат районында 1812 кеше үзмәшгуль булып теркәлеп, авыл хуҗалыгының төрле юнәлешендә үз эшен булдырган. Яңа оешкан кооперативлар саны да арта.

– Авылда мөстәкыйль эш башлаучыларның күпчелеге терлекчелек һәм кошчылык юнәлешен сайлый. Андыйларга «Агростартап» программасы буенча 476 миллион сумлык дәүләт ярдәме күрсәтелде. Башка программалар нигезендә дә дәүләт ярдәме арта, – ди авыл хуҗалыгы министры урынбасары Ленар Гарипов.

Мондый мисалларны тагын китерергә була. Нәтиҗәсе дә үзен көттермәстер, шәт. Белгечләр исәпләвенчә, киләсе елда хуҗалыкларда савым сыерларның саны – 1840 башка, атлар – 840, кош-корт 540 мең башка артырга тиеш.

«Татар-информ»

Әмма дәүләт ярдәме дә үзлегеннән килми. Аның таләпләре байтак. Кукмара, Саба, Тукай, Сарман районы хуҗалыклары дәүләт ярдәмен даими файдалана алсалар, тиешле документларны әштер-өштер генә әзерләү аркасында Әлмәт, Тәтеш, Баулы һәм кайбер башка район хуҗалыклары андый ярдәмнән быел да мәхрүм калган.

Авылда нинди дә булса эш башлаганда, мөһимрәк кыенлыклар белән очрашырга туры килә. Авырлыкларны җиңәр өчен берләшү кирәк, ди тәҗрибәле эшмәкәрләр. Ә берләшүнең иң отышлы юлы – кооперативлар төзү. Бу турыда сүз күп булса да, авыл җирлегендә яшәүче 900 меңнән артык кешенең бары тик 9 меңе генә шушы юлны сайлаган. Җитештерелгән продукциянe эшкәртеп сату, дәүләт ярдәме алу һәм башка бик күп проблемаларны бергәләшеп эшләгәндә генә уңышлы хәл итеп була.

– Муниципаль районнарга ел саен авылда яшәүчеләрне төрле кооперативларга берләштерү, яңа әгъзаларны күбрәк җәлеп итү бурычы куела. Илкүләм проектларда кооператив әгъзаларына тапшыру өчен терлек-туар, техника һәм башка кирәк-яраклар сатып алуга тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау мөмкинлеге бар. Быел 41 кооперативка 180 миллион сум акча бирелде. Башка юнәлешләргә дә ярдәм итү кала. Шуңа да карамастан, илкүләм проектны үтәүдән читтә калучылар бар. Андыйлар бөтен республиканың дәрәҗәсен төшерә, – ди Марат Җәббаров.

Камил СӘГЪДӘТШИН

Алмак бирмәк белән ярышыр

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ачык булсын, барысы да күрсен. Министрлык шуны истә тотып, мәктәптә электрон чират системасын булдырырга ниятли.

– 2022 елның апреленнән баланы беренче сыйныфка кабул итү турындагы документларны электрон рәвештә бирү мөмкин булачак. Элек онлайн рәвештә генә гариза бирeп була иде. Аннары ата-аналар биш көн кысасында мәгариф оешмаларына кирәкле документларны тапшырырга тиеш иде. Һәркем чираттагы үз урынын күреп торачак, – дип аңлатты Рәмис Мөҗипов.

Сер түгел, кайбер мәктәпләрдә белем бирү системасында бер үк нәсел кешеләре эшли. Йә ул директорның тормыш иптәше, йә бик якын туганы булып чыга. Рәмис Мөҗипов әйтүенчә, министрлык инде ике ел дәвамында мәктәпләрдә мәнфәгатьләр каршылыгын үзәктә теп тора.

– Директорның туганнары йә урынбасар, йә баш хисапчы вазыйфаларын били. Быел шундый 43 очрак теркәлгән. Нигездә бу – Кайбыч, Югары Ослан, Кама Тамагы һәм Әтнә районнары, республиканың көнчыгыш төбәкләрендә. 15 кеше эшеннән алынды, 3 кешенең вазыйфалары алмашынды, – дип аңлатты министр урынбасары.

Аның каравы мәктәптә ата-аналардан акча җыю очраклары кимегән. Рәмис Мөҗипов аңлатканча, 2021 елда ришвәтчелеккә бәйле мөрәҗәгатьләр саны ике мәртәбә кимегән.

2019 елда ата-аналардан акча җыюга карата шикаятьләр саны буенча Казанның Вахитов һәм Идел буе районнары оешмалары «алдынгылык»ны биләсә, 2021 елда беренчесеннән бер мөрәҗәгать тә килмәгән, Идел буе районыннан дүрт зар килеп ирешкән.

Рәмис Мөҗипов әйтүенчә, мөрәҗәгатьләрнең барысы да расланмый. Дөреслеккә туры килгәннәренең күрсәткече – 15 процент тирәсе.

Кайсылары алдынгы?

Ришвәтчелек белән көрәштә кайсы җирлекләр алдынгы? Бирү-алу буенча түгел, көрәштә. Татарстанның икътисад министры урынбасары, Социаль-икътисад күзәтчелек департаменты башлыгы Роман Әмирханов сүзләренчә, Чаллы бу өлкәдә аеруча активлык күрсәтә. Икенче урында – Казан, аннан Түбән Кама, Яшел Үзән һәм Әлмәт районнары. «Бу рейтинг ярдәмендә хакимият органнары ришвәтчелеккә каршы көрәштә кулланa торган алымнарына төзәтмәләр кертергә вакыт җиткәнен аңларга мөмкин», – дип шәрехләде ул бу исемлекне.

Журналистлар белән очрашкач, ришвәтчелек белән көрәштә матбугат сүзенең дә үтемле булуын искәрттеләр. Әйтик, бу елның беренче яртыеллыгында ришвәтчелекне фаш иткән 3 меңләп журналист материалы әзерләнгән. Бу да җитәрлек түгел әле. Салават Рәхимов ришвәтчелекне кисәтүдә матбугат чаралары ярдәмгә килә дигән фикердә. Бу да – бер профилактик алым.

– Әйтик, Нурлат районында бу темага – 42, Чистайда – 35, Минзәләдә 88 материал әзерләнгән иде. Бу – бик әйбәт. Әмма «кызыл зона»да булган районнар да бар. Әйтик, Азнакайда моңа кагылышлы – 5, Югары Осланда – 5, Чүпрәледә 4 материал әзерләнгән. Моңда нинди профилактика турында сүз булырга мөмкин инде? – диде Президент киңәшчесе.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

АВЫЛДА «ЙОМЫШЧЫ» ИР ДӘ КАДЕРЛЕ

Белгечләргә мөнәсәбәт

SuperJob эш эзләү порталы уздырган сораштыру нәтиҗәләре буенча укытучы иң фидакарь һәм игелекле һөнәрләр өчлегенә кергән. Беренче урында – табиблар. Сезнеңчә, иң игелекле һөнәр иясе кем ул?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сораштыруда катнашучылар беренче урында табиблар һәм шәфкать туташлары дип саный. Аларның роле коронавируска бәйле вазгыятьтә сизелерлек арткан. Һәр дүртенче кеше медицина хезмәткәрләренең хезмәтен иң игелеклесе дип белдергән. Респондентларның 14 проценты укытучылар һәм тәрбиячеләрнең эшенә югары бәя биргән. Узган елгы сораштыру нәтиҗәләреннән 4 процентка күбрәк бу. Компания белгечләре моны читтән торып уку йогынтысы дип фаразлый. Сораштыруда катнашучыларның 20 проценты кинолог, очучы, социаль хезмәткәрләрне иң миһербанлылар рәтенә керткән. Исемлектә шулай ук янгын сүндерүчеләр, коткаручылар, хәрбиләр, хәйриячеләр, урам себерүчеләр дә бар. Һәр һөнәрдә дә яхшы күңелле кешеләр очрый диючеләр юк түгел. Әмма халыкның биш проценты бер һөнәргә дә лаеклы дигән бәя бирмәгән. Сораштыруда ил буенча барлыгы 1600 кеше катнашкан.

Сез иң фидакарь, игелекле һөнәр иясе дип кемне саныйсыз?

Фоат САДРИЕВ, халык язучысы:

– Укытучы, табибтан башка өченчесе кем була икән? Бу хакта уйланганым юк. Укытучы – минем өчен иң изге һөнәр. Алар тормышка әзерләүдә гаиләдән дә күбрәк өлеш кертә. Дөньяга караш тәрбиялиләр. Башлангыч сыйныфта бигрәк тә әни кебек якын күрә идек. «Апа», «абый» дип хөрмәтләп дәштек. Без укыганда белемле укытучылар бик аз иде. Хөрмәт булгач, алар да тырышкандыр инде. Укытучыны алдау дигән нәрсә гомергә булмады. Мөгаллимнәр балаларга җылы мөнәсәбәттә иде. Безне тәрбиягә өйрәттеләр. Бик шук булсам да, әйбәт укыдым. Хәзер мәктәпкә караш үзгәрде. Бу вирус бөтен Җир шарында күзәтелә. Моны әхлак бозылу нәтиҗәсе дип саныйм. Табиблардан башка да булмый. Мәктәп рухны, күңелне тәрбияләсә, табиблар физик яктан саклый. Күптән түгел коронавирус чире белән авырдым. Җәһәннәмнән кайткан кебек булдым. Шәфкать туташларының сине кызганып караганы, эндәшкәнеңне ишетмәүчеләре дә бар. Авырганда тормышның кадерен аңладым. Чаллы хастаханәсеннән балалар өйгә алып кайтты. Мөслимдә бөтенләй башка мөнәсәбәт булды. Берсен дә хурлыйсым килми. Табибның да төрле чагы буладыр. Вазгыять тә җиңел түгел бит. Яшьләре белеп тә бетермәскә мөмкин. Авылга кайткач, ун көндә аякка бастым, табиб ике ай буе яныма килеп йөрде. Табибларның ролен шунда аңладым.

Вилдан ЗӘЙНУЛЛИН, Биектау районының Сая авылы умартачысы:

– Әлбәттә, укытучы – изге эш, мин моның белән тулысынча килешәм. Белем һәм тәрбия бирәләр, әти-әнидән кала икенче урында дип саныйм. Соңгы вакытта педагогларның дәрәҗәсе төшсә дә, минем өчен әлеге төшенчә үзгәрми. Авылда хезмәт куючы бар һөнәр дә кирәкле һәм игелекле. Авыл кешесе бөтен дөньяны туйдыра бит. Терлек асрыймы, кош-кортмы, умарта тотамы – ил табынына үз өлешен кертә. Ашаткан, туендырган кеше начар була алмый.

Вазыйх ФАТЫЙХОВ, шагыйрь, журналист:

– Укытучы һәм табибларга сабырлык бирсен. Бүгенге вазгыятьтә теләсә кем эшли алмый. Мәктәп елларында татар теле һәм әдәбият укытучысы булырга теләк бар иде. Мөгаллимнең хезмәте бик катлаулы. Дүрт оныгым бар. Аларның һәрберсе игътибар сорый. Укытучы бит сыйныфта 30 бала белән эшли. Әти-әниләрнең дә мөнәсәбәте үзгәрде. Без укыганда укытучыны тыңлый идек. Хәзер мөгаллим кыеграк сүз әйтсә дә, аны гаепли башлыйлар. Киленем укытучы булып эшли. Дәрестә баланың телефонын алып куйсаң да – аптыраш, алмасаң да. Алган очракта, әти-әни миңа барыбер икенчене сатып алачак, дип әйтәләр икән. Укытучының язмышы хәтта куркыта да әле. Башка өлкәләргә дә юкка гына күчмиләрдер. Бүгенге заманда укытучы булып эшли алмас идем. Сабырлык бик кирәк.

Хат ташучыларның хезмәтенә дә шаккатам. Гомер буе авыр букча күтәреп, җәяү йөриләр. Урамда эте дә бар. Берәр ничек хезмәтләрен җиңеләйтә торган алым юкмы икән, дип тә уйланам. Аяклары ничек түзәдер? Пенсия тарату, түләүләр өчен дә җавап бирәләр. Юлда бит нинди хәлләр булмас. Кайбер авылларга кышын кереп тә булмаска мөмкин. Авыл җирлекләре башлыкларының хезмәтен дә игелекле дип саныйм. Колхоз рәисе дә, кем генә түгел алар! Йөзләгән бурычны үтәргә туры килә. Егетләрне военкоматка әзерләп җибәрә, авылда ызгыш-талаш булса, юрист, полиция хезмәткәре ролен үти. Халык, нәрсә генә булса да, аларга мөрәҗәгать итә.

Алия ГЫЙЛЬФАНОВА, Зәй районының Түбән Биш авыл җирлеге башлыгы урынбасары:

– Минем өчен беренче урында – табиб. Чирләп китсәң, тизрәк шулар янына барырга туры килә. Бездә 4 авылда да фельдшер-акушерлык пункты бар, шәфкать туташлары бар. Халык гел йөреп тора. Укытучыга да авыл җирендә беркайчан да хөрмәт бетмәде. Бөтен кеше дә табиб һәм укытучы гына була алмый. Авылда эшләүче һәр белгеч кадерле. Хат ташучылар өлкәннәрнең бар йомышын үти. Әбиләр үзләрен дүрт күз белән көтеп тора. Алар авыл буйлап яңалык алып киләләр. Авылда хәтта эшләми торган ирләр дә бик кирәк. Андый ирләр дә берәүнең йомышын үти: кемгәдер тирес чыгаралар, кар көриләр. «Эшче кул»ларны чакырып торалар. Үлем-китем булса, беренче булып зиратка шулар килә.

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Илебез машина төзү тармагын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан электр техникасы заводы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры референты **Чистополов** Лев Владимирович; хезмәтендә ирешкән уңышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының эшләр идарәчесе **Шәрәфетдинов** Рәис Мифтах улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе 1 номерлы консультация поликлиникасының ревматология кабинеты мөдире – табиб-ревматологы **Әфләтумова** Гөлфия Нәгыйм кызына, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе 1 номерлы поликлиникасының көндезге стационары мөдире – табиб-терапевты **Кашафетдинова** Фаилә Җамалетдин кызына, Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе Саба, Мамадыш, Кукмара, Теләче районнарындагы территориаль бүлеге башлыгы урынбасары **Мәснәвиева** Мәдинә Хәмит кызына, Казан шәһәренең «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең периферия нерв системасы һәм терәк-хәрәкәтләнү аппараты функцияләре зарарланган авыруларны медицина тернәкләндерүе бүлекчәсе мөдире – бүлекчәнең табиб-терапевты **Мифтахова** Лилия Яфаз кызына, «Кукмара үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе вакытлы госпитале мөдире, табиб-инфекционисты **Сәмигуллин** Илдус Габделнур улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең травматология-ортопедия бүлекчәсе табибы – балалар хирургы **Смирнов** Олег Геннадьевичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе 2 номерлы консультация поликлиникасының кардиология бүлекчәсе табибы – балалар кардиологы **Хәбибрахманова** Лалә Гомәр кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге башлыгы **Васильева** Венера Олеговнага, Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары – хатлар һәм гражданнарны кабул итү бүлеге мөдире **Фәлахетдинова** Эльмира Илгизәр кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
2021 елның 29 ноябрендә теркәлде, № 8219

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ БОЕРЫК

22.11.2021 Казан ш. № 3555-р

2022 елга үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясын, «Оешмалар милкенә салым турында» 28 ноябрь, 2003 ел, № 49-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 1.1 статьясын, «Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелеп, Үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлеген булдыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 21.11.2014 ел, № 896 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән:

1. 2022 елга үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлеген (алга таба – Исемлек) (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. 2022 елга Исемлекне билгеләнгән тәртиптә Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. 2022 елга Исемлекне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында (адресы: http://www.mzio.tatarstan.ru/www.mzio.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
4. Бу боерык 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары М.А.Рогожкинга йөкләргә.

Министр **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Искәрмә: Исемлек Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы сайтына (https://http://www.mzio.tatarstan.ru/mzio.tatarstan.ru/perechen-obektov-nedvizhimosti-na-2022-gob.htm.) урнаштырылган.

«МИН БИТ «ХАЛЫК АРТИСТЫ» ТҮГЕЛ, СЕҢЛЕМ...»

Сагыну

«Халык артистлары» дигән китапка музыка белгече Дания Гыйматдинова аның турында очерк язарга теләге барлыгын әйткәч, сөекле җырчыбыз Зифа Басыйрова шулай ди.

«...Шушы җавапны ишеткәч, Дания ханым, ачыргаланып, йөрәк әрнүе белән:

– Зифа апа, ничек инде Сез халык артисты түгел, хәтта Мәскәүдәге концертларыгызга да тамашачылар агылып йөриләр, залларда басып торырга да урын калмый иде бит, – диде. Аңа каршы Зифа апа:

– И үскәнем, бәхетсез йолдыз астында туганмындыр. Башта ятимлек ачысын татыдым. Аннан соң түрәләрнең гаделсезлеге хезмәтемне юкка чыгарды, – дип җавап кайтарды». Бу юллар 1978 елда Зифа апа белән ял йортында бергә булган Әминә Гобәйдуллина-Камалетдинова истәлекләреннән алынды.

Сандугач сайрар өчен туган шикелле, Зифа Басыйрова да җырлар өчен дөньяга килгән. Татар халкында җырга карата тирән мәгънәле бер әйтем бар – «Бер йөрәктә туган җыр мең йөрәкне кузгата». Зифа Басыйрова да йөрәк түреннән дәрьядай ташып чыккан моңнары белән меңнәргә рухи байлык өләшә, җаннарын дәвалый, күңелләрендә якты хыяллар уята, яшәүгә көч өсти. Халкыбызның кайнар мәхәббәтен яулаган җырчының иҗаты белән балачагымнан ук бүгенгә кадәр рухланып, аннан илһам алып яшәвемне бераз гына шәрехләп үтмәсәм, язмабыз бик үк тулы булмас кебек.

Сүземне балачактан башлыйм әле. 1960 нчы еллар. Миңа 5–6 яшьләр чамасы булгандыр. Җәйнең иң матур ае – август ахырлары иде. Бер кичне әти белән әни сөйләшәләр: «Әйдә әле, карт, иртәгә Уфаны урап кайтыйк. Балаларның укырга барыр вакытлары да җитә. Арзанрак бәягә мәктәп формалары очрамасмы, төпчегебезнең дә (бусы мин булам инде) аягына кияргә калмады. Өммелхәят түткәйнең дә күптәннән авылга кайтканы юк, бер барганда аның да хәлләрен белеп чыгарбыз». Шушы сүзләрне ишетүем булды, алар каршына килеп бастым да: «Мин дә сезнең белән Уфага барам, сездән калмыйм, ияртмәсәгез, артыгыздан кача-кача булса да барыбер барам», – дип елап та алдым. «Ярар-ярар, шыңшыма, барырсың, түлке әйбер сорап теңкәгә тиясе булсаң, кара аны!..» дигән «шарт» белән әнкәй мәрхүмә ризалашты. Әткәйнең андый вакытларда һичкайчан авыз ачып сүз әйткәнен хәтерләмим. Көнозын базарларда, кибетләрдә йөреп арыгач, әни әйткән Өммелхәят апаларга киттек. Үз йортлары белән торалар икән. Нәкъ авылдагыча. Без бераз хәл алуга, түткәйнең самавыры да кайнап чыкты, тәмле аш исләре дә таралды. Тамак туйдырганнан соң арыганнар бетеп, рәхәт изрәү басты. Шул вакыт аргы баштагы бүлмәдән йөрәк кылларын өзәрлек моңлы җыр ишетелде. Әти дә, әни дә, мин дә җыр ишетелгән шул бүлмәгә ашыктык. «Менә бу галәмәт патефон дип атала, туганкайларым. Күргәнегез юктыр әле. Шушы пластмасс тәлинкәләргә әртисләрнең тавышлары язылган. Ә бу аппарат шул авазларны безгә ишеттерә инде», – дип аңлатты апабыз.

Йокларга яткач, башта бер генә уй булды: «И-их, биреп җибәрсен иде апабыз безгә шул «патефон» дигәннәрен!» Уянгач та беренче сүзем шул булды: «Әни, сорагыз әле, бирсен әле безгә шуны, сорагыз, зинһар өчен...» «Әйберләр болай да күп җыелды, улым, бирсә, үзең күтәреп алып кайтасыңмы соң?» Кайтмыйммы соң инде! Бирсен генә! Ничек ризалаштырганнардыр, белмәдем, биргән бит, Ходайның рәхмәте. Трамвай тукталышына кадәр дә, аннан соң да кулдан төшермәдем мин аны. Авылга кайтып җиткәннән соң да 3–4 чакрым җәяү атлыйсы бит әле, җитмәсә, бик көчле яңгыр явып үткән, һавасы да бик бөркү... Мин бернәрсәгә карамый, кызу-кызу адымнар белән атлыйм да атлыйм. Тизрәк өйгә кайтып җитәсе, теге «могҗиза»ның тавышын тыңлыйсы килә... Өйгә кайтып кергәндә шыбыр тиргә баткан идем. Менә шул көннән безнең өйдә дә күңелгә якын милли җыр-моңнарыбыз ишетелә башлады. 5–6 яшьтә генә булсам да, мин шул пластинкалардагы язуларны шартлатып укый идем. Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Фәридә Кудашева, Мәрьям Рахманкулова, Зифа Басыйрова... Авылыбызда, бәлки, бердәнбер патефонга куелган пластинкалардан җыр тыңларга дип, бала-чага, күрше әби-апалар безгә җыела иде. Бигрәк тә «Рамай», «Шөгер», «Озату», «Шомыртым», «Су буйлап» кебек халык моңын сыйдырган җырларны тыңлаганда өлкәннәрнең күзләре яшьләнүе әле дә хәтеремдә. Халык арасында зур популярлык алган ул көйләрнең күренекле җырчы Зифа Басыйрова репертуарыннан булуын соңыннан, үсә төшкәч кенә белдем.

Укырга кергәч, атнага бер тапкыр була торган җыр дәресләренә мин шул җырчыларның җырларын өйрәнеп бара идем. Җырга мәхәббәтем дә әнә шуннан башланды дип беләм. Үсә төшкәч, мәктәптә үткәрелгән барлык концертларда, кичәләрдә җыр белән катнаша идем. IX класста укыганда район күләмендә «Алло! Без талантлар эзлибез!» конкурсында катнашып, беренче урынны алуым да истә. Студент елларында да бер генә концерттан да калдырмадылар диярлек. Еллар үткәч, нурлы да, дәртле дә Казаныбызга да, һичшиксез, әнә шул моңнар тартып китергәндер. Җыр сәнгатебезнең чишмә башында торган фидакарь җырчыларыбызга мин гомерем буе сокланып яшим, аларга рәхмәтем чиксез. Ни кызганыч, аларның күбесенә шул чорның авырлыкларын, алай гына да түгел, гаделсезлекләрен татырга туры килгән. Зифа Басыйровага бигрәк тә! Радиода эшләгән елларымда Зифа Басыйрова язмаларыннан әзерләнгән концертларны күп алып барырга туры килде. Магнитофоннан агылган үзәк өзгеч бу моңнар безне ыгы-зыгылы тормыштан якты балачак елларыбызга, туган якларыбызга кайтара, яшьлектә сөйгән ярларыбызны хәтердә яңарта, ата-бабаларыбызның ерак үткәненә сәфәр кылдыра, милли хисләребезне, милли горурлыгыбызны уята. Шул вакыт, Тукайчалатыбрак әйткәндә, «Шушы җырчының «халык артисты» дигән исемгә хакы юкмы?» – дип кычкырасым килә иде.

Дөрес, сөекле җырчыбызның якты истәлеген мәңгеләштерү җәһәтеннән соңгы елларда шактый гына изге гамәлләр эшләнгән. Җырчының туган ягы Мөслимдә җыр конкурслары үткәрелә, район мәдәният йортына һәм район үзәгендәге бер урамга аның исеме бирелгән. Казанның да Совет районындагы яңа урамнарның берсе Зифа Басыйрова исемендә. Шулай ук Казанда ул яшәгән йортка Истәлек тактасы куелачак дигән сөенечле хәбәрне дә ишеттем. Бирсен генә Ходай! Әлбәттә, боларның һәммәсе дә ифрат дәрәҗәдә куанычлы гамәлләр! Инде шушыларга өстәп, халык әллә кайчан үзе биргән «халык артисты» дигән исемне рәсмиләштереп, иҗатының иң югары дәрәҗәгә ирешүен дәлилләп, таҗ да киертеп куйсак Зифа апабызның башына!.. Моңа, беренчедән, мәрхүмәнең рухы шатланыр, икенчедән, талантлы кызының хезмәтенә, иҗатына халкыбызның олы ихтирам һәм хөрмәт күрсәтүе булыр иде. Ә моңа җырчының оныклары – газиз улы Рафаэльнең (1938–1995) балалары (алар исән булырга тиеш) ничек сөенерләр иде, ә?!

Халык моңнары – борын-борыннан килгән әманәт, дибез. Әнә шул изге әманәтне зур саклык, хөрмәт белән, олылап, сәнгать югарылыгына күтәреп халкына тапшырган гүзәл җырчы, җыр сәнгатенең асыл йөзек кашы, ярлы батрак Габделбасыйр белән Фәрхинур кызы Зифаны еллар аша булса да, олылыйк, хөрмәтлик әле, милләттәшләр! Язмабызга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Зифа Басыйрованың 100 еллыгы уңаеннан «Халык җырчысы» дигән мөрәҗәгате (ә ул инде башта ук телгә алынган китапны ачып җибәрә) белән нокта куйыйк: «Җыр – кешенең гомерлек юлдашы», – дип халык юкка гына әйтмидер. Сөенеч килсә, җыр кешене уята, кайгы-хәсрәт килсә – юата. Ләкин кем җырлый бит әле! Бик сирәкләрнең генә тавышына, язмышына халыкның бөтен тарихы сыя. Ерак гасырлардан килгән иңрәү дә, сабый бала беренче йөреп киткәндә чыккан шат авазлар да, сөйгән яр белән хушлашкандагы сагыш та гүя синең йөрәгеңә кагыла. Шуңа да һәркемнең күңелен биләп алган җырчыларны «халык җырчысы» диләр. Зифа Басыйрова шундый җырчы иде. Халык бәгыреннән өзелеп төшкән һәм озак елларга халык күңелендә калган җырчы. Бүген дә аның тавышы, аның моңы безне битараф калдырмый. Димәк, җырчы яши, татар җыры яши!

Тәлгать ХАМАТШИН.
Башкортстан, Бүздәк

Спорт

Барыбер үзенә карата

Камилә Вәлиева бар дөньяны шаккатырды. Фигуралы шуу буенча Гран-при ярышларының Сочида узган этабында Казан кызы берьюлы өч рекордны яңартты. 15 яшьлек спортчының киләсе ел башында буласы Олимпия Уеннарында да җиңү яулый аласына бик азлар гына шикләнә. Күз генә тимәсен!

Кыска (87,42 балл) һәм ирекле (185,29) программаларда дөнья рекордын яңарткан Камилә, аңлашыла инде, гомуми сумма (272,71) белән дә үзенең элеккеге күрсәткечләрен узып китте. Мондый саннар белән ир-егетләр ярышын да отып була! «Миңа хатын-кызлар белән ярышу ошый. Хатын-кызлар белән ир-егетләрне чагыштыру дөрес түгел», – ди Камилә.

15 яшьлек спортчының чыгышы күп белгечләрне таң калдыра. «Әйтерсең, ул бөтенләй башка планетадан! Һәрхәлдә, хәзер шулай тоела», «Ул – бөтен дөньяның хәзинәсе. Юкка гына Олимпиада фавориты булып саналмый», «Тутберидзе командасының фанаты түгелмен, әмма моңа кадәр Камилә кебек спортчының булмавын танырга туры килә», «Әле ярый бераз җитешсез яклары бар. Алайса, ул кеше түгел, лабораториядә ясаганнар дип уйлар идең» – әнә шулай дип язалар аның турында.

Аңлашыла инде, Камиләне яратмаучылар да җитәрлек. Казан кызының чыгышында хисләрнең аз булуын әйтәләр, хөкемдарларның артык яхшы бәя бирүен язалар. Олимпиада якынлашкан саен мондый фикерләр арта гына торачак. Камиләгә бозда шуудан бигрәк, әнә шул басымга каршы торырлык көч тупларга туры киләчәк. Ярыш саен рекорд белән гаҗәпләндергән татар кызын киләсе атнада Осакада узачак Гран-при финалы көтә. Декабрь ахырында Россия чемпионаты булачак. Гыйнвар уртасында – Европа чемпионаты. Әнә шул сынаулардан соң төп вакыйга – Пекинда узасы Олимпия Уеннары килеп җитә. Хәтерләсәгез, 2018 елда узганында Россия спортчылары нибары 2 алтын медаль отып, шуның берсен татар кызы Алинә Заһитова яулаган иде.

instagram.com

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә ~~465 сум~~ 404,04 сум

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә ~~1000,92 сум~~ 859,08 сум

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+

КҮРШЕ КЫЗЫ ГӨЛФИЯ

Редакция эшләре белән районнарга барып чыксаң, һич көтмәгәндә авылдашлар да очрап куя. Мондый чакларда бигрәкләр дә рәхәт булып китә. Күрше кызы, Яшел Үзән районының Айдар авылы имамы Юныс абый Гарифуллинның кызы Гөлфия дә Апас районындагы Шыгай авылында яшәп ята икән. Кош балалары кебек таралышып беткәннәр болар. Үзе дә ерактан, Балтач районыннан килен булып төшкән әниләре Гөлчирә апа бүген Гүзәлен – Сарман ягыннан, Гөлфиясен – Апастан, Гөлчәчәге белән Ленарын – Казаннан, Рифатын Яшел Үзәннән көтә.

Чит җирләрдә яшәп яткан авылдашының тормышы сокланырлык, якын-тирәдәгеләр аны ярату хисе белән генә телгә алса, тагын да күңеллерәк. Гөлфия белән дә шулай килеп чыкты. Апас халкын бәйләгән әйберләре белән таң калдыра икән ул. Хәзер инде бәйләгән әйберләр модада түгел, кибеттә ни теләсәң, шул бар, дип әйтерләр кайберәүләр. Ә менә Гөлфия алай уйламый, кибеттән өс киемен дә сирәк кенә сатып ала. Зәвыклы, заманча булса, үзеңнекенә җитәме соң, дигән фикердә.

– Мин 7 яшьтә чигә башладым, – дип искә ала Гөлфия. – Иң беренче итеп чәчәкләп кульяулык чиктем. Кайдан өйрәндең дисезме? Әнием бик оста бәйләүче, чигүче иде. Мин аның бервакытта да тик кенә утырганын хәтерләмим. Бер минут вакыты булса да, аягөсте генә ике-өч күз бәйләп китә иде бугай ул. Биш бала үстергәч, күп итеп терлек-туар асрагач, вакыты да булмагандыр инде. Оекбашлар, бияләйләр бәйләргә мине дәү әнием Хәфәзә өйрәтте.

Гөлфия инде 8 нче сыйныфта укыган чакта ук, дус-ишләрен кызыктырып, арка җылысы бәйләп кия. Шуннан китә инде. Күлмәк, итәк яки фуфайка, кофта дисеңме – нәрсәгә тотынса, шуңа кулы ята. Шул вакыттан туктаганы да юк.

– Кич җитте исә, кулым үзеннән-үзе бәйләүгә барып тотына. Телевизор карасам да, хәтта китап укысам да, мин дөньямны онытып бәйлим дә бәйлим. Бу шөгыль миңа шундый ләззәт бирә. Бөтен тәнем, рухым белән рәхәтләнеп ял итәм. Карамыйча бәйли алгач, күзләремә дә зыян килми. Мин инде бәйләмсез бер минут тора алмам кебек. Үлчәү эшләре белән дә мәшәкатьләнеп тормыйм. Гәүдәгә генә куеп карыйм. Килеп чыкмаса, бушрак яки тыгызрак булса, аптырап тормыйм, сүтәм дә яңадан бәйлим. Бер дә авырсынмыйм. Заманча булсын дип, модадан артка калмаска тырышам. Шуңа күрә үрнәкләрне интернеттан эзлим. Кайберләрен үзем уйлап чыгарам.

Бүтән эше юктыр дип уйлый күрмәгез. Гөлфия Апас районының Аккуҗа авылы мәктәбендә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли. Өстәвенә музыка, рәсем, хезмәт дәресләре алып бара. Төрле чаралар, бәйгеләр оештыруга да ул җаваплы. Мәктәп балаларын да кул эшләренә өйрәтеп бетергән инде ул. Районда «Сәләт» иҗат үзәге аңа Аккуҗада бәйләү түгәрәге оештырырга мөмкинлек биргән. Кул эшләрен тәкъдим итеп, төрле күргәзмәләрдә катнашалар. Нәтиҗәсе дә бар. «Без – бергә!» фестивалендә район буенча икенче урынга лаек булганнар. Аңа кадәр Гөлфия Шыгай авылында тәрбияче дә булып эшләгән әле. Кызганыч, балалар булмау сәбәпле, бакчаны япканнар. Анда йөргән сабыйлар апалары бәйләгән уенчыкларны бүген дә хәтерли, диләр.

Хуҗалыкта мал-туарны, кош-кортны да күп асрый бу гаилә. Ничек җитешәсең, дигән сорауга Гөлфия елмаеп кына җавап бирде:

– Терлекләрне күбрәк ирем Фәнил карый. Йорт эшләрендә балаларым булыша.

Балалар дигәннән, өйдә бәләкәе – 7 нче сыйныфта укучы Фәридәсе генә калган инде. Кадрия Яшел Үзән шәһәренең Үзәк хастаханәсендә – шәфкать туташы. Читтән торып логопед булырга да укый. Ялларга гына кайта ала. Фәнисләрен быел җәй армия сафларына алганнар. Биш ай булды инде, дип көннәрне санап тора Гөлфия. Юкка гына түгел. Бергә җыелудан ямь таба алар. Тәмле ризыкны да бергәләп пешерәләр, тәрәзә төбендәге шау чәчәктә утырган гөлләрне дә бергә-бергә үстерәләр. Яңа бәйләгән киемнәре турында фикер алышалар. Берәр яңа бизәк тапсалар, күңелләре сөенеч белән тула. Ул да булмый, әтиләре бүләк иткән тегү машинасы артына утыралар. Кадрия белән Фәридәсе дә үзе кебек, кул эшләренә бик оста. Куллары һәр эшкә ятып торганнарына сөенеп бетә алмыйлар. Хәер, кызларын гына түгел, тирә-як авыллардагы күпме баланы һөнәрле иткән бит ул, шуңа күрә рәхмәт сүзләрен дә күп ишетә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЯЗМЫШЛАР КҮКТӘ ЯЗЫЛА

Кайбыч районының Шуширмә авылында яшәүче Таңсылу Вәлиева да әнә шулай дип күңелен юата.

Дөньяга сау-сәламәт булып туган кыз ике яшендә авырый башлый. Әти-әнисе табибларга күрсәткәч, алар сабыйның канына инфекция эләгүен әйтә. Шуның аркасында гәүдәсенең сул ягы хәрәкәтләнми башлый.

– Башкалар кебек булмавыма бик читенсендем. Балачакта аеруча кыен иде. Әле ярый дус-ишләрем, сыйныфташларым мине чит итмәде. Киресенчә, хәлемне аңлап, якын итеп тордылар. Аларның яратуы, үз итүе миңа көч бирде, – дип сөйли Таңсылу. – Әти белән әни дә, бер дә кимсенмә, дип үстерделәр. Авыруны бит аны сорап алмыйсың. Димәк, миңа шулай язган булган. Тормышта үз кыяфәтеңнән читенсенеп елап утырып булмый. Ничек тә яшәргә кирәк. Уң як аяк-кулым сулы өчен дә эшли. Мин шулай ияләндем инде.

Таңсылу мәктәпне тәмамлагач, Казан төзелеш көллиятендә белем алган. Өйдән торып кына эшли. Быел яңадан КХТИның социаль хезмәт бүлегенә читтән торып укырга кергән. Өйдә буш вакытларын әрәм итми ул. Әнисе белән кухняда мәш киләләр.

– Әнием Гөлсу – пешекче. Бик уңган. Аның бар ризыгы тәмле була. Күп кенә ризыкларны заказга да сорап пешертәләр, – ди Таңсылу. – Тормышта сөенече дә, көенече дә күп була. Икесен дә кичердем. Әти белән әни шулкадәр бер-берсен яратып яшәде. Без аларның ачуланышканын да күрми идек. Әти һәрчак үзенең ягымлы сүзен әйтте. Мине һәм сеңлемне яратып кына торды. Миңа карата аеруча җылы мөнәсәбәттә иде. Тормышта югалып калма, үз юлыңны тап, беркайчан да кимсенмә, дип әйтә иде. Кызганыч, безнең арадан китүенә 11 ел булды инде. Ул фаҗигале төстә һәлак булды. Атлар дип җенләнгән иде. Сабантуйларда гел чабышларда катнашты. 2010 елның сентябрендә янгын чыкты. Әти, атларны коткарам дип, үзе утка кереп китте. Шуннан исән килеш чыга алмады ул.

Хәзерге вакытта алар әтисенең энесе Илгизәр абый белән төп йортта бергә яшиләр икән. Кыз абыйсына да чиксез рәхмәтле.

– Ул безне үз балаларыдай якын итте. Әти үлеменнән соң ятимлекне сизмәсеннәр дип тырышты. Әнием дә бигрәк көчле рухлы булган икән. Хәзер уйлыйм да сокланып куям. Авыру бала дип бер дә кимсетмәде. Киресенчә, үземне ничек бар, шулай яратырга өйрәтте. Син башкалардан ким түгел, дип кенә торды. Әни аркасында мин үземне авыруга санамыйм. Үзем дә әнигә охшарга тырышам. Алдагы көннәрдә без аны рәхәттә яшәтсәк иде, – ди ул.

Таңсылу үзен ничек бар, шулай кабул итәргә өйрәнгән. Бер дә тик тормый, бер кул белән әллә ниләр эшләп куя икән.

– Барысына да ияләшәсең. Дөрес, баштарак эшләрне авыррак башкара идем. Хәзер исә ияләштем. Камыр ризыклары пешерү җанга шулкадәр рәхәтлек бирә! Кухняда кайнашканда бар борчуларымны онытам. Берни уйламыйм. Ял итәм, – ди ул.

Таңсылуның үзеннән ике яшькә генә кече сеңлесе Гөлшат читтән торып КАИда белем ала икән. Ул да үз тормышын үзе күрергә өйрәнгән. Бер кибеттә кондитер булып эшли. Әниләренең кызларын пешерергә өйрәтүе бушка китмәгән.

Таңсылу физик мөмкинлеге чикләнгән хатын-кызлар арасында узучы «Татарстан энҗесе» бәйгесендә дә катнашырга гариза биргән. Сеңлесе Гөлшат бу хакта интернетта күреп алып, апасын катнашырга үгетләгән. Таңсылу бәйгегә әзерләнә башлаган инде. Үзе язган шигырьләрне сөйләячәк. Иҗат җимешләре белән күп кенә бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар да яулаган ул. Шигырьләрдә – күңел халәтем, ди үзе.

– Аларны язгач, күңел бушый. Тикмәгә генә кулга каләм алмыйсың бит инде. Әтиемне дә бик сагынам, әби-бабамны да. Үземне якын иткән барлык кешеләргә рәхмәтем шигъри юлларга салына, – ди Таңсылу. – Бер зур хыял белән яшим. Югары белем алгач, Казанга күченәсем килә. Эшкә урнашып, үз куышымны булдырып яшәргә иде. Әлегә гаилә кору кебек уйлар белән янмыйм. Миңа болай да рәхәт. Әмма тәкъдиреңнән узып булмый. Ни язса, шул булыр. Шуңа күрә мин якыннарыма сәламәтлек һәм гомер телим. Алар миңа бик кирәк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7404 данә
Гомуми тираж – 17211 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 374

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+